| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ |
| --- | --- |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

19 август 2021 ел № 69

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль предприятиеләренә, учреждениеләренә гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатларында аларның исемнәрен бирү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәте рәисе урынбасарының 2021 елның 30 июнендәге, ТГ-П16-8721 номерлы хатын үтәү йөзеннән, Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль предприятиеләренә, учреждениеләренә гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатларында аларның исемнәрен бирү тәртибе турындагы Балтач район Советының 2017 елның 3 маенда кабул ителгән 84 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Нигезләмәнең 1.5 пунктының икенче абзацында «эшлекләләре, » сүзеннән соң «Бөек Ватан сугышы Геройлары (1941 – 1945 еллар)» дигән сүзтезмәсен өстәргә;

1.2. Нигезләмәнең 2.6 пунктына түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә: «Бөек Ватан сугышы геройларының исемнәре (1941 – 1945 еллар) үлеп 1 ел үткәннән соң бирелә.».

2.Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм baltasi.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Балтач район Советының гражданнарның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау, законлылык һәм хокук тәртибе, җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин